**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# О внесении изменений в Административный регламент предоставления Министерством лесного хозяйства Республики Татарстан государственной услуги «Проведение государственной экспертизы проекта освоения лесов»

В связи с внесением изменений в Лесной кодекс Российской Федерации **постановляю**:

1. Внести в Административный регламент предоставления Министерством лесного хозяйства Республики Татарстан государственной услуги «Проведение государственной экспертизы проекта освоения лесов», утвержденный Указом Президента Республики Татарстан от 27 декабря 2013 года № УП-1291 «Об утверждении Административного регламента предоставления Министерством лесного хозяйства Республики Татарстан государственной услуги «Проведение государственной экспертизы проекта освоения лесов» (с изменениями, внесенными указами Президента Республики Татарстан от 15 января 2016 года № УП-6 и от 8 октября 2016 года № УП-911), следующие изменения:

а) пункт 2.4 изложить в следующей редакции:

«2.4. Срок предоставления государственной услуги – не более чем 30 дней со дня поступления проекта освоения лесов в Министерство, а в случае проведения экспертизы изменений в проект освоения лесов, подготовленных на основании акта лесопатологического обследования, – не более чем 10 рабочих дней со дня их поступления в Министерство.»;

б) пункт 3.13 дополнить словами «, а в случае проведения экспертизы изменений в проект освоения лесов, подготовленных на основании акта лесопатологического обследования, – в течение двух рабочих дней с даты регистрации заявления»;

в) пункт 3.24 дополнить словами «, а в случае проведения экспертизы изменений в проект освоения лесов, подготовленных на основании акта лесопатологического обследования, – в течение четырех рабочих дней после дня получения секретарем Экспертной комиссии заявления на предоставление государственной услуги и проекта освоения лесов»;

г) пункт 3.29 дополнить словами «, а в случае проведения экспертизы изменений в проект освоения лесов, подготовленных на основании акта лесопатологического обследования, – в течение двух рабочих дней после дня

подписания заключения государственной экспертизы членами Экспертной комиссии»;

д) пункт 3.35 дополнить абзацем следующего содержания:

«В случае проведения экспертизы изменений в проект освоения лесов, подготовленных на основании акта лесопатологического обследования, действия, предусмотренные пунктом 3.33 настоящего Административного регламента, осуществляются в течение одного рабочего дня после утверждения заключения государственной экспертизы, предусмотренные пунктом 3.34 настоящего Административного регламента, – в течение одного рабочего дня после регистрации сопроводительного письма с приложениями.»;

е) блок-схему предоставления государственной услуги «Проведение государственной экспертизы проекта освоения лесов» изложить в редакции согласно приложению.

2. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань,Кремль
22 ноября 2016 года
№ УП-1046

Приложение
к Указу Президента
Республики Татарстан

от « 22 » ноября 2016 года

№ УП- 1046

Блок-схема
предоставления государственной услуги
«Проведение государственной экспертизы проекта освоения лесов»

Прием и регистрация документов в день поступления заявления

↓

Проверка документов в течение трех дней (двух рабочих дней)* с даты регистрации заявления → Отказ в предоставлении государственной услуги

↓

Проведение государственной экспертизы проекта освоения лесов в течение 15 дней (четырех рабочих дней)* после дня получения секретарем Экспертной комиссии заявления на предоставление государственной услуги

↓

Положительное заключение государственной экспертизы | Отрицательное заключение государственной экспертизы

↓

Утверждение заключения государственной экспертизы в течение четырех дней (двух рабочих дней)* после дня подписания заключения государственной экспертизы членами Экспертной комиссии

↓

Направление заявителю заключения государственной экспертизы и проекта освоения лесов на бумажном носителе в течение семи дней (двух рабочих дней)* после утверждения заключения государственной экспертизы

---

Примечание:
* В скобках указывается срок осуществления действий в случае проведения экспертизы изменений в проект освоения лесов, подготовленных на основании акта лесопатологического обследования.

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан «Урманнарны үзләштерү проектына дәүләт экспертизасы үткәрү» дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Урман кодексына үзгәрешләр кертелү белән бәйле рәвештә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан «Урманнарны үзләштерү проектына дәүләт экспертизасын үткәрү» дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге ПУ-1291 номерлы Указы белән расланган (Татарстан Республикасы Президентының 2016 елның 15 гыйнварындагы ПУ-6 номерлы һәм 2016 елның 8 октябрендәге ПУ-911 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан «Урманнарны үзләштерү проектына дәүләт экспертизасын үткәрү» дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 2.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты проект Министрлыкка кергән көннән соң 30 көннән дә артып китмәскә, ә урманнарны үзләштерү проектына урман патологиясен тикшерү акты нигезендә әзерләнгән үзгәрешләр кертелгән очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты алар Министрлыкка кергән көннән соң 10 эш көненнән дә артып китмәскә тиеш.»;

б) 3.13 пунктка «, ә урманнарны үзләштерү проектына урман патологиясен тикшерү акты нигезендә әзерләнгән үзгәрешләргә экспертиза уздырылган очракта – гариза теркәлгән датадан ике эш көне дәвамында» дигән сүзләр өстәргә;

в) 3.24 пунктка «, ә урманнарны үзләштерү проектына урман патологиясен тикшерү акты нигезендә әзерләнгән үзгәрешләргә экспертиза уздырылган очракта – Эксперт комиссиясе секретаре тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза һәм урманнарны үзләштерү проекты алынган көннән дүрт эш көне дәвамында» дигән сүзләр өстәргә;

г) 3.29 пунктка «, ә урманнарны үзләштерү проектына урман патологиясен тикшерү акты нигезендә әзерләнгән үзгәрешләргә экспертиза

уздырылган очракта – Эксперт комиссиясе әгъзалары тарафыннан дәүләт экспертизасы бәяләмәсе имзаланган көннән ике эш көне дәвамында» дигән сүзләр өстәргә;

д) 3.35 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

« Урманнарны үзләштерү проектына урман патологиясен тикшерү акты нигезендә әзерләнгән үзгәрешләргә экспертиза уздырылган очракта, әлеге Административ регламентның 3.33 пунктында каралган гамәлләр дәүләт экспертизасы бәяләмәсе расланганнан соң бер эш көне эчендә, әлеге Административ регламентның 3.34 пунктында каралганнары теркәп җибәрелгән хатны кушымталары белән теркәгәннән соң бер эш көне эчендә башкарыла.»;

е) «Урманнарны үзләштерү проектына дәүләт экспертизасын үткәрү» дәүләт хезмәтен күрсәтүнең блок-схемасын кушымта нигезендә редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2016 ел, 22 ноябрь
№ ПУ-1046

Татарстан Республикасы
Президентының
2016 елның «22» ноябрендәге
ПУ-1046 номерлы Указына
кушымта

«Урманнарны үзләштерү проектына дәүләт экспертизасын үткәрү»
дәүләт хезмәтен күрсәтүнең
блок-схемасы

Гариза алынган көнне документларны кабул итү һәм теркәү

↓

Гариза теркәлгән датадан соң өч көн (ике эш көне)* дәвамында документларны тикшерү → Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту

↓

Эксперт комиссиясе секретаре тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза алынганнан соң 15 көн (дүрт эш көне)* дәвамында урманнарны үзләштерү проектына дәүләт экспертизасы уздыру

↓

Дәүләт экспертизасы биргән уңай бәяләмә | Дәүләт экспертизасы биргән тискәре бәяләмә

↓

Эксперт комиссиясе әгъзалары тарафыннан дәүләт экспертизасы бәяләмәсе имзаланган көннән дүрт көн (ике эш көне)* дәвамында дәүләт экспертизасы бәяләмәсен раслау

↓

Дәүләт экспертизасы бәяләмәсе расланганнан соң җиде көн (ике эш көне)* дәвамында кәгазь чыганакта дәүләт экспертизасы бәяләмәсен һәм урманнарны үзләштерү проектын гариза бирүчегә юллау

---

Искәрмә:
* Җәя эчендә, урманнарны үзләштерү проектына урман патологиясен тикшерү акты нигезендә әзерләнгән үзгәрешләр кертелгән очракта, гамәлләрне башкару вакыты күрсәтелә.